РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» __08__ 2025г. №865

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 12.12.2019 ел, № 970 карары белән расланган Ютазы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексында каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә үз компетенциясе чикләрендә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы, административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы, «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында»гы 30.07.2010 ел, № 60-ТРЗ Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы башкарма комитеты к а р а р и т т е:

1. Үз компетенциясе чикләрендә Ютазы муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексында каралган административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы башкарма комитетының "Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге хакында (үзгәрешләр белән: 2024 елның 17 декабренә)" 12.12.2019 ел, № 970 карары белән расланган беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Исемлекнең 3.16 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| Ст. 3.16 КоАП РТ | Түләүле муниципаль парковкалардан (парковка урыннарыннан) файдалануның муниципаль хокукый актта билгеләнгән тәртибен бозу транспорт чарасын түләүле муниципаль парковкада (парковка урынында) урнаштырган өчен түләмәүдә йә муниципаль хокукый актта билгеләнгәннән кимрәк күләмдә түләү кертүдә, йә парковкадан файдаланган өчен түләү өчен муниципаль хокукый актта билгеләнгән сроктан соңрак түләү кертүдә чагыла | Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге җитәкчесе<br>Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге баш белгече |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе С.П. Самонина